# ОТЧЕТ
## о деятельности контрольно-счетной палаты Нижнекамского муниципального района за 2020 год

Настоящий отчет о деятельности контрольно-счетной палаты Нижнекамского муниципального района (далее - контрольно-счетная палата) подготовлен в соответствии с требованиями Федерального закона от 07.02.2011 № 6-ФЗ «Об общих принципах организации и деятельности контрольно-счетных органов субъектов Российской Федерации и муниципальных образований» и Положением о контрольно-счетной палате. Представленный отчет содержит обобщенную информацию о результатах деятельности контрольно-счетной палаты по внешнему муниципальному финансовому контролю, проведенному в 2020 году в соответствии с планом работы.

В течение года в план работы контрольно-счетной палаты вносились изменения в связи с поступлением внеплановых заданий по решению комиссии по координации работы по противодействию коррупции в Нижнекамском муниципальном районе, по запросу Счетной палаты Республики Татарстан, по предложениям исполнительных комитетов Нижнекамского муниципального района и города Нижнекамска, по решениям коллегии контрольно-счетной палаты.

Организация работы в отчетном году основывалась на принципах законности, объективности, эффективности, независимости и гласности, являющихся базовыми для эффективного функционирования органа внешнего финансового контроля.

Деятельность в отчетном году осуществлялась в соответствии полномочиями контрольно-счетной палаты, особое внимание уделялось контролю реализации результатов деятельности, своевременному и качественному принятию мер объектами контроля по устранению выявленных нарушений, а также проведению профилактической работы в целях минимизации и недопущения нарушений.

### Основные итоги деятельности

В соответствии с планом работы контрольно-счетной палаты за 2020 год проведено 16 контрольных мероприятий в отношении 35 объектов контроля и 93 экспертно-аналитических мероприятий.

Подготовлено 16 актов, 8 аналитических записок и 85 экспертных заключений, в том числе проведены 34 экспертизы проектов решений о бюджетах и отчетах об исполнении бюджетов по 17 муниципальным образованиям; проведена финансово-экономическая экспертиза проектов муниципальных программ и внесения изменений в программы и подготовлено 31 заключение.

При квалификации нарушений в 2020 году контрольно-счетная палата Нижнекамского района, как и в предыдущие годы, применяла Классификатор нарушений, выявляемых в ходе внешнего государственного аудита (контроля), одобренного Советом контрольно-счетных органов при Счетной палате Российской Федерации.

Основные показатели, характеризующие деятельность палаты, представлены в таблице 1.

Таблица 1

Основные показатели деятельности контрольно-счетной палаты

| Показатели | 2020 год |
|---|---|
| ***Контрольная деятельность*** | |
| Общее количество проведенных контрольных мероприятий (ед.) | 16 |
| Количество объектов, охваченных при проведении контрольных мероприятий (ед.) | 35 |
| ***Экспертно-аналитическая деятельность*** | |
| Общее количество проведенных экспертно-аналитических мероприятий (ед.), в т.ч.: | 93 |
| *- подготовлено экспертных заключений* | *85* |
| *- подготовлено аналитических записок* | *8* |
| Подготовлено методических документов | - |
| Выявленный объем нарушений (тыс. руб.) | 59 312,0 |
| Кроме того, неэффективное использование бюджетных средств (тыс. руб.) | 3 090,4 |
| ***Реализация результатов контрольных и экспертно-аналитических мероприятий*** | |
| Принято мер и восстановлено средств по мероприятиям, всего (тыс. руб., %), в том числе: | 69 878,4 |
| *- по мероприятиям, проведенным в 2020 году* | *62 142,0 (99,6%)* |
| *- по мероприятиям, проведенным в 2019 году* | *7 736,4* |
| Фактические затраты на содержание контрольно-счетной палаты (тыс. руб.) | 7969,8 |
| Количество материалов, направленных в правоохранительные органы (ед.) | 4 |
| Количество направленных представлений и предписаний, в том числе: | 12 |
| *- исполнено представлений и предписаний (результативность, %)* | *12 (100%)* |
| Количество протоколов об административной ответственности, оформленных КСП, в том числе: | 6 |
| *- количество Постановлений суда о привлечении должностных лиц к административной ответственности (результативность, %)* | *5 (83,3%)* |
| *- начислено штрафов (тыс. руб.)* | *25,0* |
| *- поступило в бюджет штрафов (тыс. руб.)* | *30,0 (за 2019 г.)* |
| Привлечено лиц к дисциплинарной ответственности | 13 |
| Должностные лица контрольно-счетной палаты */ % сотрудников, имеющих высшее образование | 6 чел./ 100% |
| Проведено заседаний Коллегии | 26 |
| Рассмотрено вопросов на заседаниях Коллегии контрольно-счетной палаты | 117 |
| Количество сотрудников, прошедших повышение квалификации (чел.) | 3 |

** председатель, заместитель председателя, аудиторы, инспекторы.*

В рамках проведенных мероприятий в 2020 году установлено 207 нарушений на общую сумму 62 млн 402 тыс. руб.

Всего в 2020 году объектами контроля, на основании представлений и рекомендаций контрольно-счетной палаты, приняты меры по устранению выявленных нарушений и недостатков, предотвращению нанесения материального ущерба муниципальному образованию и возмещению причиненного вреда на общую сумму 62 млн 142 тыс. руб. или на 99,6%, в том числе восстановлено средств в бюджет – 6 млн 175 тыс. и устранено нарушений на сумму 55 млн 967 тыс. руб.

Должностные лица контрольно-счетной палаты в отчетном году в соответствии с соглашениями о совместной деятельности привлекались Счетной

палатой Республики Татарстан для проведения трех контрольных мероприятий:

- проверка неиспользуемых объектов недвижимости, находящихся в муниципальной собственности;
- проверка использования средств бюджета Республики Татарстан, выделенных на реализацию национального проекта «Здравоохранение» и Программы «Развитие здравоохранения Республики Татарстан до 2020 года» в рамках развития материально-технической базы детских поликлиник и детских поликлинических отделений медицинских организаций в 2018-2019 годах;
- проверка использования средств бюджета, выделенных в 2019 году и истекшем периоде 2020 года на реализацию национального проекта «Демография – Старшее поколение» в рамках выполнения мероприятий «Приобретение и использование автотранспорта в целях доставки на селе лиц старше 65 лет в медицинские организации».

Во исполнение протокола расширенного заседания комиссии по координации работы по противодействию коррупции в Нижнекамском муниципальном районе, в отчетном году проведено 3 контрольных мероприятия: в Каенлинском, Нижнеуратьминском и Афанасовском сельских поселениях при выдаче выписок из похозяйственных книг.

Кроме того, в 2020 году по предложениям исполнительных комитетов Нижнекамского муниципального района и города Нижнекамска, контрольно-счетной палатой Нижнекамского района проведены четыре контрольных мероприятия по проверке использования муниципального имущества.

В рамках экспертно-аналитической деятельности, контрольно-счетной палатой в 2020 году проводились экспертизы 18 проектов бюджетов и 18 отчетов об исполнении бюджетов, из них 34 экспертизы проведены в соответствии с соглашениями о передаче полномочий по внешнему финансовому контролю по следующим поселениям Нижнекамского муниципального района: город Нижнекамск, пгт Камские Поляны и 15 сельских поселений, в том числе: Афанасовское, Елантовское, Каенлинское, Кармалинское, Краснокадкинское, Красноключинское, Майскогорское, Макаровское, Нижнеуратьминское, Простинское, Сосновское, Старошешминское, Сухаревское, Шереметьевское, Шингальчинское. Проведены экспертизы 12 проектов решений о внесении изменений в бюджеты, финансово-экономические экспертизы проектов муниципальных программ (внесения изменений в программы) - подготовлено 31 заключение и 6 заключений на проекты нормативных правовых актов органов местного самоуправления.

Кроме того, ежеквартально проводился мониторинг использования высокотехнологичного медицинского оборудования, закупленного для государственных и муниципальных учреждений здравоохранения Нижнекамского муниципального района, информация по которому направлена в Счетную палату Республики Татарстан.

По итогам проведенных в 2020 году контрольных и экспертно-аналитических мероприятий в целях устранения выявленных нарушений, предотвращения нанесения материального ущерба муниципальному образованию, возмещения причиненного вреда, пресечения и предупреждения нарушений, контрольно-

счетной палатой в адрес руководителей учреждений направлено 12 представлений, по которым объектами контроля приняты меры, направленные на устранение нарушений.

Также по результатам мероприятий, проведенных контрольно-счетной палатой в отчетном периоде, руководителями проверенных учреждений к дисциплинарной ответственности привлечено 13 должностных лиц.

В течение отчетного периода по итогам контрольных и экспертно-аналитических мероприятий было внесено 6 предложений о принятии, изменении и дополнении ряда нормативных правовых актов в Нижнекамском муниципальном районе, городе Нижнекамске, регулирующих бюджетный процесс и сферу управления муниципальной собственностью. При принятии нормативных правовых актов, органами местного самоуправления учтены 3 предложения контрольно-счетной палаты, остальные находятся на стадии рассмотрения.

Отчеты о результатах проведенных контрольных и экспертно-аналитических мероприятий направлялись Главе Нижнекамского муниципального района и Совету Нижнекамского муниципального района.

В 2020 году возбуждено 6 дел об административных правонарушениях, которые были направлены на рассмотрение мировым судьям. По 5 административным делам мировыми судьями приняты решения о привлечении должностных лиц к административной ответственности, в том числе по 2 делам - в виде штрафов на общую сумму 25 тыс. руб., по 3 делам – замечания и предупреждение. По одному делу производство было прекращено.

Административные дела возбуждены по следующим статьям Кодекса об административных правонарушениях РФ:

- 15.15.5-1 КоАП РФ (Невыполнение государственного (муниципального) задания) – 2 протокола;

- 15.15.6 КоАП РФ (Нарушение требований к бюджетному (бухгалтерскому) учету, в том числе к составлению, представлению бюджетной, бухгалтерской (финансовой) отчетности) – 2 протокола;

- 15.15.15 КоАП РФ (Нарушение порядка формирования государственного (муниципального) задания) – 2 протокола.

В отчетном году в рамках осуществления деятельности по противодействию коррупции с должностными лицами контрольно-счетной палаты проведена разъяснительная работа:

- по вопросам соблюдения ограничений, запретов, требований предотвращения и урегулирования конфликта интересов;

- лицам, замещающим муниципальные должности, указано на необходимость своевременного и достоверного предоставления сведений о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, в том числе в электронном формате и на бумажном носителе.

В соответствии с соглашением о взаимодействии, материалы по итогам контрольных мероприятий, проведенных в 2020 году, направлены в городскую

прокуратуру.

За отчетный период повышение квалификации прошли 3 сотрудника контрольно-счетной палаты по программам «Контрактная система в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд» - 2 сотрудника и 1 сотрудник по программе «Государственные и муниципальные закупки».

На официальном сайте Нижнекамского муниципального района размещаются годовые отчеты о деятельности контрольно-счетной палаты, результаты проведенных контрольных и экспертно-аналитических мероприятий. Кроме того, в соответствии с законодательством о контрактной системе, информация о результатах аудита закупок размещается на официальном сайте zakupki.gov.ru.

**2020 елда Түбән Кама муниципаль районының**
**контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында**
**ХИСАП**

Түбән Кама муниципаль районы контроль-хисап палатасы (алга таба - контроль-хисап палатасы) эшчәнлеге турындагы әлеге хисап «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмә нигезендә әзерләнде. Тәкъдим ителгән хисапта тышкы муниципаль финанс контроле буенча контроль-хисап палатасының эш планы нигезендә 2020 елда үткәрелгән эшчәнлеге нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат тупланган.

Ел дәвамында контроль-хисап палатасының эш планына, контроль-хисап палатасы коллегиясе карарлары буенча, Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре башкарма комитетлары тәкъдимнәре буенча, Татарстан Республикасы Хисап палатасы соравы буенча, Түбән Кама муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе карары буенча планнан тыш биремнәр керүгә бәйле рәвештә, үзгәрешләр кертелде.

Хисап елында эшне оештыру тышкы финанс тикшерүе органының нәтиҗәле эшчәнлеге өчен нигез булып торган законлылык, объективлык, нәтиҗәлелек, бәйсезлек һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнде.

Хисап елында эшчәнлек контроль-хисап палатасы вәкаләтләре нигезендә башкарылды, эшчәнлекнең нәтиҗәләрен тормышка ашыруны контрольдә тотуга, ачыкланган бозуларны бетерү буенча контроль объекты тарафыннан үз вакытында һәм сыйфатлы чаралар күрүгә, шулай ук бозуларны минимальләштерү һәм булдырмау максатларында, профилактик эш үткәрүгә аерым игътибар бирелде.

**Эшчәнлекнең төп нәтиҗәләре**

Контроль-хисап палатасының 2020 елга эш планы нигезендә 35 контроль объектына карата 16 тикшерү чарасы һәм 93 эксперт-аналитик чара үткәрелде.

16 акт, 8 аналитик язма һәм 85 эксперт бәяләмәсе әзерләнде, шул исәптән 17 муниципаль берәмлек буенча бюджет һәм бюджет үтәлеше турында хисап хакында карарлар проектларына 34 экспертиза үткәрелде; муниципаль программалар проектларына финанс-икътисадый экспертиза һәм программаларга үзгәрешләр кертү үткәрелде һәм 31 бәяләмә әзерләнде.

2020 елда хокук бозуларны квалификацияләгәндә, Түбән Кама районының контроль-хисап палатасы, алдагы еллардагы кебек үк, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы контроль-хисап органнары Советы тарафыннан хупланган тышкы дәүләт аудиты (контроль) барышында ачыкланган Бозулар классификаторын кулланды.

Палатаның эшчәнлеген характерлаучы төп күрсәткечләр 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица

Контроль-хисап палатасы эшчәнлегенең төп күрсәткечләре

| **Күрсәткечләр** | **2020 ел** |
|---|---|
| ***Контроль эшчәнлеге*** | |
| Үткәрелгән контроль чараларның гомуми саны (бер.) | 16 |

| | |
|---|---|
| Контроль чараларын үткәргәндә колачланган объектлар саны (бер.) | 35 |
| ***Эксперт-аналитик эшчәнлек*** | |
| Үткәрелгән эксперт-аналитик чараларның гомуми саны (бер.), шул исәптән: | 93 |
| *- эксперт бәяләмәләр әзерләнде* | *85* |
| *- аналитик язмалар әзерләнде* | *8* |
| Методик документлар әзерләнде | - |
| Ачыкланган бозу күләме (мең сум) | 59 312,0 |
| Моннан тыш, бюджет акчаларын нәтиҗәсез файдалану (мең сум) | 3 090,4 |
| ***Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләрен тормышка ашыру*** | |
| Чаралар буенча чаралар кабул ителде һәм акчалар кире кайтарылды, барлыгы (мең сум,%), шул исәптән: | 69 878,4 |
| *- 2020 елда үткәрелгән чаралар буенча* | *62 142,0 (99,6%)* |
| *- 2019 елда үткәрелгән чаралар буенча* | *7 736,4* |
| Контроль-хисап палатасын тотуга фактик чыгымнар (мең сум) | 7969,8 |
| Хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны (бер.) | 4 |
| Җибәрелгән күрсәтмәләр һәм кисәтмәләр саны, шул исәптән: | 12 |
| *- күрсәтмәләр һәм кисәтмәләр үтәлгән (нәтиҗәлелек, %)* | *12 (100%)* |
| КХП тарафыннан рәсмиләштерелгән административ җаваплылык турында беркетмәләр саны, шул исәптән | 6 |
| *- вазыйфаи затларны административ җаваплылыкка тарту турында суд карарлары саны (нәтиҗәлелек ), %)* | *5 (83,3%)* |
| *- штрафлар салынды (мең сум)* | *25,0* |
| *- бюджетка штрафлар керде (мең сум)* | *30,0 (за 2019 г.)* |
| Дисциплинар җаваплылыкка тартылган затлар | 13 |
| Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары */% югары белемле хезмәткәрләр | 6 чел./ 100% |
| Коллегия утырышлары уздырылды | 26 |
| Контроль-хисап палатасы коллегиясе утырышларында мәсьәләләр каралды | 117 |
| Квалификация күтәрүне узган хезмәткәрләр саны (кеше) | 3 |

** рәис, рәис урынбасары, аудиторлар, инспекторлар.*

2020 елда үткәрелгән чаралар кысаларында 62 млн 402 мең сумлык 207 бозу очрагы ачыкланды.

2020 елда барлыгы контроль-хисап палатасы күрсәтмәләре һәм тәкъдимнәре нигезендә контроль объектлары тарафыннан ачыкланган бозуларны һәм җитешсезлекләрне бетерү, муниципаль берәмлеккә матди зыян китерүне булдырмау һәм 62 млн 142 мең сумлык зыянны кире кайтару буенча чаралар күрелде, ягъни 99,6% ка, шул исәптән бюджетка – 6 млн 175 мең сум акча кире кайтарылды һәм 55 млн 967 мең сумлык бозулар бетерелде.

Хисап елында контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары уртак эшчәнлек турындагы килешүләр нигезендә өч контроль чара үткәрү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан җәлеп ителде:

- муниципаль милектәге файдаланылмый торган күчемсез милек объектларын тикшерү;

-2018-2019 елларда балалар сырхауханәләре һәм медицина оешмаларының балалар сырхауханәләре бүлекчәләренең матди-техник базасын үстерү кысаларында

«Сәламәтлек саклау» милли проектын һәм «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклавын үстерү» программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын файдалануны тикшерү;

- «65 яшьтән өлкәнрәк булган затларны медицина оешмаларына китерү максатларында, автотранспорт сатып алу һәм аннан файдалану» чараларын үтәү кысаларында «Демография – Өлкән буын» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга 2019 елда һәм 2020 елның узган чорында бүлеп бирелгән бюджет акчаларын файдалануны тикшерү.

Түбән Кама муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясенең киңәйтелгән утырышы беркетмәсен үтәү йөзеннән, хисап елында 3 контроль чара үткәрелде: Каенлы, Түбән Уратма һәм Афанас авыл җирлекләрендә хуҗалык китапларыннан өземтәләр биргәндә.

Моннан тыш, 2020 елда Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре башкарма комитетлары тәкъдимнәре буенча, Түбән Кама районы контроль-хисап палатасы тарафыннан муниципаль милекне куллануны тикшерү буенча дүрт контроль чара үткәрелде.

Эксперт-аналитик эшчәнлек кысаларында, контроль-хисап палатасы тарафыннан 2020 елда 18 бюджет проектына һәм бюджет үтәлеше турында 18 хисапка экспертиза үткәрелде, шулардан 34 экспертиза Түбән Кама муниципаль районының түбәндәге җирлекләренә тышкы финанс контроле буенча вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә үткәрелде: Түбән Кама шәһәре, Кама Аланы штп һәм 15 авыл җирлеге, шул исәптән: Афанас, Елантау, Каенлы, Кармалы, Кызыл Чапчак,  Красный Ключ, Майская Горка, Макаровка, Түбән Уратма, Прости, Сосновка, Иске Чишмә, Сухрау, Ширәмәт, Шәңгәлче. Бюджетка үзгәрешләр кертү турында 12 карар проектына экспертиза, муниципаль программалар проектларына финанс-икътисадый экспертиза (программаларга үзгәрешләр кертү) үткәрелде - 31 бәяләмә һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары проектларына 6 бәяләмә әзерләнде.

Моннан тыш, квартал саен аның буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Хисап палатасына җибәрелгән Түбән Кама муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләре өчен сатып алынган югары технологияле медицина җиһазларын куллану мониторингы уздырылды.

2020 елда үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитика чаралары нәтиҗәләре буенча, ачыкланган бозуларны бетерү, муниципаль берәмлеккә матди зыян китерүне булдырмау, китерелгән зыянны каплау, бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатыннан, контроль-хисап палатасы тарафыннан учреждениеләр җитәкчеләре адресына 12 күрсәтмә җибәрелгән, алар буенча контроль объектлары тарафыннан бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрелде.

Шулай ук хисап чорында контроль-хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча тикшерелгән учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан 13 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Хисап чоры дәвамында контроль һәм эксперт-аналитика чаралары нәтиҗәләре буенча Түбән Кама муниципаль районында, Түбән Кама шәһәрендә бюджет процессын һәм муниципаль милек белән идарә итү өлкәсен җайга салучы кайбер норматив хокукый актларны кабул итү, үзгәртү һәм тулыландыру турында 6

тәкъдим кертелде. Норматив хокукый актларны кабул иткәндә җирле үзидарә органнары тарафыннан контроль-хисап палатасының 3 тәкъдиме исәпкә алынды, калганнары карау стадиясендә.

Үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында хисаплар Түбән Кама муниципаль районы Башлыгына һәм Түбән Кама муниципаль районы Советына җибәрелде.

2020 елда җәмәгать судьяларына карап тикшерү өчен җибәрелгән административ хокук бозулар турында 6 эш кузгатылды. 5 административ эш буенча җәмәгать судьялары тарафыннан вазыйфаи затларны административ җаваплылыкка тарту турында карарлар кабул ителде, шул исәптән 2 эш буенча - гомуми суммасы 25 мең сумлык штрафлар рәвешендә, 3 эш буенча – искәртмәләр һәм кисәтүләр. Бер эш буенча башкару туктатылды.

Административ эшләр РФ Административ хокук бозулар кодексының түбәндәге статьялары буенча кузгатылды:

- РФ Административ хокук бозулар кодексының 15.15.5-1 (дәүләт (муниципаль) биремен үтәмәү) - 2 беркетмә;

- РФ Административ хокук бозулар кодексының 15.15.6 (бюджет (бухгалтерия) исәбенә таләпләрне бозу, шул исәптән бюджет, бухгалтерия (финанс) хисаплылыгын төзү, тапшыру) - 2 беркетмә;

- РФ Административ хокук бозулар кодексының 15.15.15 (дәүләт (муниципаль) биремен формалаштыру тәртибен бозу) - 2 беркетмә.

Хисап елында коррупциягә каршы тору буенча эшчәнлекне тормышка ашыру кысаларында контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары белән аңлату эшләре алып барылды:

- мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу таләпләрен, чикләүләрне, тыюларны үтәү мәсьәләләре буенча;

- муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шул исәптән электрон форматта һәм кәгазьдә үз вакытында һәм дөрес мәгълүмат бирү зарурилыгы күрсәтелде.

Үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә, 2020 елда үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча материаллар шәһәр прокуратурасына җибәрелде.

Хисап чорында контроль-хисап палатасының 3 хезмәткәре квалификация күтәрү курслары узды: «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы» программасы буенча - 2 хезмәткәр һәм 1 хезмәткәр «Дәүләт һәм муниципаль сатып алулар» программасы буенча.

Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында еллык хисаплар, үткәрелгән контроль һәм экспертиза-аналитик чаралар нәтиҗәләре урнаштырыла. Моннан тыш, контракт системасы турындагы законнар нигезендә, сатып алулар аудиты нәтиҗәләре турында мәгълүмат zakupki.gov.ru рәсми сайтында урнаштырыла.